СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ

КАРАР

03.04.2026

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

№7-37

с. Нижний Услон

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Советның кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1.1. "Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында" Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел № 31-179 карары;

1.2. "Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау турында" Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 16.06.2020 ел № 81-331 карары;

1.3. "Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу мәгълүматларны бозу гамәлдә булмаса, үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Түбән Ослан авыл җирлеге

Советының 07.03.2023 ел № 31-175 карары;

1.4. «Түбән Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 11.09.2017 ел № 33-127 карары .

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга мөмкин.

Председательлек итүче,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев